ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның бишенче абзацында «диссертацияләр яклау советлары булдырылган оешмалар, мәҗбүри нөсхәне» сүзләреннән соң «эшләп чыгаруны,» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«мәдәни мирас объектларын саклау буенча фәнни-проектлау документлары – мәдәни мирас объектларын саклау эшләрен башкару өчен фәнни-тикшеренү, фәнни-эзләнү, проектлау, смета һәм хисап документлары;

проектлау документлары – текст рәвешендәге һәм карталар (схемалар) рәвешендәге материаллары булган һәм капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны тәэмин итү өчен архитектура, функциональ-технологик, конструктив һәм инженер-техник чишелешләрне билгели торган теләсә кайсы төр саклагычлардагы документлар.»;

3) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен илтеп җиткерү**

Документлар җитештерүчеләр, шул исәптән полиграфия оешмалары аша, түбәндәгеләрне илтеп җиткерәләр:

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә басмаларның, рәсми документларның, аудиовизуаль продукциянең, электрон басмаларның һәм катнаш документларның өчәр мәҗбүри нөсхәсен;

Татарстан Республикасы Дәүләт архивына Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган барлык төр документларның берәр мәҗбүри нөсхәсен, моңа сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен басмалар керми;

Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсенә сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен басмаларның икешәр мәҗбүри нөсхәсен.

Документлар җитештерүчеләр электрон рәвештәге басмаларның документ җитештерүченең квалификацияләнгән электрон имзасы белән таныкланган берәр мәҗбүри нөсхәсен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт архивына илтеп җиткерәләр.

Мәдәни мирас объектларын саклау буенча фәнни-проектлау документларының һәм проектлау документларының мәҗбүри нөсхәсен илтеп җиткерү срокларын һәм тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган башка документларны илтеп җиткерү сроклары һәм тәртибе Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган тиешле документлар төрләренә карата “Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында” Федераль закон нигезендә билгеләнә.»;

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. **Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен алучы оешмаларның бурычлары**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә басмаларның, электрон рәвештәге басмаларның, рәсми документларның, аудиовизуаль продукциянең, электрон басмаларның һәм катнаш документларның мәҗбүри нөсхәсен туплау, аның сакланышын һәм аннан файдалануны тәэмин итү йөкләнә.

Татарстан Республикасы Дәүләт архивына, сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен басмалардан тыш, мәгълүмати басмаларны туплау, дәүләт теркәвенә алу, дәүләт библиографик исәбен һәм статистик исәпне алып бару, чыгару, Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган барлык төр документларның сакланышын һәм алардан файдалануны тәэмин итү йөкләнә.

Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсенә алар өчен мәгълүмати басмаларны туплау, дәүләт теркәвенә алу, дәүләт библиографик исәбен һәм статистик исәпне алып бару, чыгару, сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен басмаларның мәҗбүри нөсхәсенең сакланышын һәм аннан файдалануны тәэмин итү йөкләнә.»;

5) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен даими саклау**

Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен даими саклау Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган тиешле документлар төрләренә карата әлеге Законның 7 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә, Татарстан Республикасы Дәүләт архивына, Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсенә йөкләнә.

Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәләрен даими саклауны һәм җәмәгать тарафыннан алардан файдалануны тәэмин итүче, фондлары Татарстан Республикасы документларының милли китапханә-мәгълүмат фондын барлыкка китерә торган оешмалар күрсәтелгән фондларның сакланышын тәэмин итү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.»;

6) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен илтеп җиткерүне тикшереп тору**

Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен документларны кабул итеп алучыларга илтеп җиткерүне тикшереп тору Татарстан Республикасы документлары мәҗбүри нөсхәсенең тиешле төрләрен дәүләт теркәвенә алуны, дәүләт библиографик исәбен һәм статистик исәпне алып баруны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Дәүләт архивына, Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсенә йөкләнә. Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен илтеп җиткермәү, үз вакытында һәм тулысынча илтеп җиткермәү турындагы белешмәләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы документлары мәҗбүри нөсхәсенең тапшырылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыручы органына җибәрелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *

Казан,Кремль
2017 ел, 20 июль
№ 61-ТРЗ